| МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.07.2017 Казан шәһәре № под-1252/17

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүчеләрнең һәркем өчен ачык булган, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган мәгълүматлар урнаштырылган «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацион челтәрендә сайтларның адреслары һәм (яки) сайт битләре, мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында " 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 20.2 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17.2 статьясы нигезендә б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүчеләрнең һәркем өчен ачык булган, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган мәгълүматлар урнаштырылган «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә сайтларның адреслары һәм (яки) сайт битләре, мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен расларга
2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Премьер-министр урынбасары
Татарстан Республикасы Премьер – министры Э. Н. Фәттахов

Расланган
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 21.07 2017 ел, под – 1252/17 боерыгы белән

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүчеләрнең , шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граҗданлык хезмәткәрләренең һәркем өчен ачык булган, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган мәгълүматлар урнаштырылган «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә сайтларның адреслары һәм (яки) сайт битләрен, аларда мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүчеләрнең , шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граҗданлык хезмәткәрләренең һәркем өчен ачык булган, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган мәгълүматлар урнаштырылган «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә сайтларның адреслары һәм (яки) сайт битләрен, аларда мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен билгели:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүчеләрнең , һәркем өчен ачык булган, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган үз мәгълүматларын урнаштырылган «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә сайтларның адреслары һәм (яки) сайт битләре турында мәгълүмат бирү тәртибе

сайт турында мәгълүматларны кабул итү һәм эшкәртү тәртибе;

сайт турындагы мәгълүматның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибе.

1.2. «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында " 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлеше нигезендә һәркем өчен ирекле алу мөмкин булган мәгълүмат тцшенчәсе астында һәркемгә мәгүлум һәм башка мәгълүмат аңлашыла. Шул ук вакытта мәгълүматка үтемлелекне чикләү булмау чикләнмәгән затлар даирәсе

тарафыннан мәгүлүматны тоткарлыксыз алу һәм үз теләге белән урнаштырылган мәгълүматны гражданлык хезмәткәре яки гражданин ризалыгыннан башка куллану мөмкинлеген дә бирә

1.3. Граждан хезмәткәре яки Граждан шәхесен ачыкларга мөмкинлек бирүче мәгълүматлар сыйфатында түбәндәге мәгълүматларның җыелма яисә берсе була ала: фамилиясе һәм исеме, фотография, хезмәт урыны.

II.Сайт турында мәгълүматларны кабул итү һәм эшкәртү тәртибе

2.1. Сайт турында мәгълүматларны урнаштыралар:

граждан - Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә кергәндә (алга таба - граждан хезмәте) дәүләт гражанлы хеэмәтенә керер алдыннан өч календарь ел эчендәге мәгълүмат ;

гражданлык хезмәткәре - ел саен хисап елыннан соң килгән календарь елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча.

2.2. Сайт турындагы белешмәләр гражданнар һәм граждан хезмәткәрләре тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән форма (алга таба - Форма) буенча бирелә.

2.3. Һәркем өчен мөмкин булган мәгълүмат граждан хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәү кысаларында урнаштырылган очракта Формада чагылдырылырга тиеш түгел.

2.4. Тутырылган Форма гранданлык хезмәткәре тарафыннан Татарстан Республикасы Премьер - министры урынбасары-Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры боерыгы (алга таба - Премьер - министр урынбасары-министр урынбасары) белән билгеләнеп куелган Министрлыкның кадрлар сәясәте бүлеге хезмәткәренә тапшырыла.

2.5. Җаваплы зат «Интернет» челтәрен кулланып күрсәтелгән мәгълүматларның тулылыгын, дөреслеген тикшерә, шәхси имза куя, Форманы алган көндә әлеге тәртип буенча журналга мәгълүматлар кертә.

2.6. Тутырылмаган кырларны үз эченә алган Форма кабул ителергә тиеш түгел.

2.7. Граждан тапшырган формада дөрес булмаган мәгълүматлар ачыкланган очракта Министрлыкның кадрлар сәясәте бүлеге аны дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куюдан баш тарту турында кичекмәстән хәбәр итә.

2.8. Сайтлар турында мәгълүматлар җаваплы зат тарафыннан «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәте кадрлары составының бердәм мәгълүмат системасында " гражданлык хезмәткәрләренең шәхси карточкасына кертелә.

2.9. Граждан хезмәткәрләре һәм гражданнар тарафыннан тәкъдим ителгән формалар Министрлыкның кадрлар сәясәте бүлегендә биш ел дәвамында саклана, шуннан соң Министрлыкта шәхси мәгълүматларны эшкәртү кагыйдәләре белән билгеләнгән тәртиптә юкка чыгарылырга тиеш.

## III. Сайт турындагы мәгълүматның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибе

3.1. Граждан хезмәткәрләре тәкъдим иткән сайтларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Премьер - министр урынбасары – министр (Премьер - министр урынбасары вазыйфаларын башкаручы зат) боерыгы буенча гамәлгә ашырыла

3.2. Язма рәвештә тәкъдим ителгән түбәндәге мәгълүмат тикшерү өчен нигез булып тора:

хокук саклау органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан;

сәяси партияләрнең даими эшләүче җитәкче органнары һәм закон нигезендә теркәлгән сәяси партияләр булмаган башка Гомумроссия, төбәкара һәм региональ иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан;

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы;

гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чаралары.

3.3. Җаваплы зат тикшерү үткәрү турында боерык чыккан көннән соң ике эш көне дәвамында язма рәвештә гражданлык хезмәткәренә аңа карата тикшерү башлану турында хәбәр итә.

3.4. Гражданлык хезмәткәрләре тәкъдим иткән Сайт турындагы мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү җаваплы зат тарафыннан

«Интернет» челтәрендә урнаштырылган  һәркем өчен ачык мәгълүматны эзләү һәм күрсәтелгән мәгълүматның электрон күчермәләрен (скриншотлар) булдыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

3.5. Гражданлык хезмәткәре тикшерү барышында һәм нәтиҗәләре буенча язма формада аңлатмалар , өстәмә материаллар бирергә хокуклы.

3.6. Әлеге тәртипнең  3.5 пунктында күрсәтелгән аңлатмалар., тикшерү материалларына өстәмә буларак биреләләр.

3.7. Тикшерү материаллары һәм тикшерү барышында җыелган мәгълүмат тикшерү үткәрү турында боерык чыккан көннән соң 10 эш көненнән дә артмаган вакытка Премьер-министр урынбасары - министрга тапшырыла.

3.8. Тикшерү нәтиҗәләре буенча 5 көнлек срокта Премьер - министр урынбасары - министр карар кабул итә:

граждан хезмәткәренә юридик җаваплылык чараларын куллану өчен нигезләрнең булмавы турында;

граждан хезмәткәренә юридик җаваплылык чараларын куллану турында;

хокук бозу билгеләре, экстремистик эшчәнлеккә катнашы булган җинаять билгеләре булганда тикшерү материалларын дәүләт органнарына җибәрү турында.

3.9. Премьер-министр урынбасары - министрның кабул ителгән карары турында җаваплы зат ике эш көне дәвамында тикшерү үткәрелгән граждан хезмәткәренә язмача хәбәр итә.

3.10. Сайтлар турында белешмәләр Премьер - министр урынбасарының язма ризалыгы белән,  аңа карата тикшерү үткәрелгән  граҗданлык хезмәткәренә, шулай ук даими эшләүче сәяси партияләрнең җитәкче органнарына һәм закон нигезендә теркәлгән башка Гомумроссия, төбәкара һәм региональ иҗтимагый берләшмәләргә, сәяси партияләр булмаган Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы,   , бөтенроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чараларына,    хокук саклау органнарына бер үк вакытта хәбәр ителергә мөмкин,

3.11. Тикшерү материаллары Министрлыкның кадрлар сәясәте бүлегендә өч ел дәвамында саклана, шуннан соң архивка тапшырыла.

## IV. Сайт турында мәгълүматларны тапшырмау өчен җаваплылык

4.1 Сайт турындагы белешмәләрне тапшырмаган очракта граждан дәүләт гражданлык хезмәтенә билгеләнә алмый, ә дәүләт гражданлык хезмәткәре Дәүләт гражданлык зезмәтендә эшләү хокукын югалта.

4.2. Дәүләт гражданлык хезмәткәре тарафыннан Сайт турындаги мәгълүматны тапшырмау гражданлык хезмәтеннән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.